Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы

Зур Нөркәй авыл җирлеге

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№ 1 13.11.2019

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй

авыл җирлегендә халык җыены нәтиҗәләре турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары нигезендә 2019 елның 13 ноябрендә «2020 елда һәр балигъ булмаган гражданнан 200 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, Зур Нөркәй авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан, дүрт һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләрдән тыш, һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү дә керә:
- Зур Нөркәйдә (Сабантуй, 9 Май, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне) бәйрәмнәрне үткәрү өчен бүләкләр алу;
- махсуслаштырылган техниканы карап тоту – “Беларус-82.1” тракторы (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт күрсәтү өчен түләү);
- Зур Нөркәй авылы Болын урамында яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру;
- Зур Нөркәй авылының Болын урамында 300 м озынлыкта вак таш түшәмәсен (вак таш ташу) ремонтлау;
- Зур Нөркәй авылы территориясендә көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны вакытлыча җыю урыннарын җыештыру;
- район “Сарман” газетасында некрологларны бастырып чыгару;

"ӘЙЕ, ЮК».

2019 елның 13 ноябрендәге гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 412 кеше, гражданнар җыенында катнашучылар саны 255 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 255 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлегендә, Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авылында узган халык җыенын халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә, дип танырга.

2. «Сез 2020 елда Зур Нөркәй авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан, дүрт һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдән тыш, 200 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә килешәсезме?» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны («за»-255, «против " -0) танырга.

- Зур Нөркәйдә (Сабантуй, 9 Май, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне) бәйрәмнәрне үткәрү өчен бүләкләр алу;

- махсуслаштырылган техниканы карап тоту – “Беларус-82.1” тракторы (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт күрсәтү өчен түләү);

- Зур Нөркәй авылы Болын урамында яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру;

- Зур Нөркәй авылының Болын урамында 300 м озынлыкта вак таш түшәмәсен (вак таш ташу) ремонтлау;

- Зур Нөркәй авылы территориясендә көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны вакытлыча җыю урыннарын җыештыру;

- район “Сарман” газетасында некрологларны бастырып чыгару.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнашкан: http//sarmanovo.tatar.ru һәм махсус мәгълүмат стендларында: Зур Нөркәй авылы, С.Рафиков урамы, 32 йорт.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Р. М. Гайсин